**I.Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре**

**Сыйныф** 1А сыйныфы (татар төркеме)
**Сәгать саны:** 66 сәгать, атнага 2 сәгать.
"Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары" 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан, "Мәгариф" нәшрияты, 2011ел. нигезендә төзелгән планлаштыру
**Дәреслек :**

1) Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова .Әлифба: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) . – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012.

2) Ф.Ф.Харисов, Г.Д.Сираҗиева.Татар теле: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) . – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012

Эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:

1.Программа: "Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары" (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. Казан. "Мәгариф" нәшрияты, 2011)

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе "Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе"нең төп гомуми белем бирү баскычында гомуми башлангыч белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе "Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе"нең 2018-2019 уку елына укыту планы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2018 ел).

**Фәнне үзләштерүнең шәхси, предметара нәтиҗәләре**

**Шәхси нәтиҗәләр.**

**Шәхси универсаль уку гамәлләре (ШУУГ):**

- "Гаилә", "туган ил", "мәрхәмәтлелек", "башкаларга карата түземлелек" төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү;
- Туган республикага, гаиләгә, туганнарга карата хөрмәт, әти-әнине ярату; үз милләтеңне ярату, татар булуың белән горурлану;
- укуга карата кызыксыну хисе булу, укучы ролен үзләштерү;
- әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләрен һәм геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү.

**Предметара нәтиҗәләр.**

**Регулятив универсаль уку гамәлләре (РУУГ):**

- Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү.
- Укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү.
- Укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү.
- Эш сыйфатына бәя бирә белү.
- Эш барышында гади генә эш приборлары белән эш итә белү (линейка, бетергеч, карандаш ).

**Танып - белү универсаль уку гамәлләре (ТБУУГ):**

- Дәреслек белән эш итә белү.
- Хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп уку.

- Этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап уку.
- Текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсен төшенү.
- Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.
- Укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны дәреслектән таба белү.
- Предметларны, чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белү.
- Укылган яки тыңланган зур булмаган текстның эчтәлеген сөйли белү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре (КУУГ):**

- Дәрестә һәм төрле ситуацияләрдә диалогта катнаша белү
- Укытучының, классташларның сорауларына җавап бирү;
- Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү.
- Башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү.
- Парларда эшли белү.

**1 нче сыйныф өчен укыту предметының программа эчтәлеге**

| Темалар |
|---|
| **1.Телдән әзерлек чоры дәресләре**<br>**Танышу**.<br>**Безнең мәктәп**<br>**Безнең гаилә.**<br>**Ашамлыклар.**<br>**Кеше.**<br>**Өс-баш, аяк киемнәре**.<br>**Уеннар.**<br>**Авылда**.<br>**Кошлар**.<br>**Шәһәрдә.**<br>**Бәйрәмнәр.** |
| 2. **Әлифба чоры.**<br>Хәрефләрдән иҗекләр төзү, иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр төзеп уку. Сүзтезмәләрдән җөмләләр төзү күнекмәләре тәрбияләү. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Эчтәлеген аңлап,кирәкле урыннарда паузалар ясап, сүз басымын дөрес куеп уку.<br>Әлифба чорында татар һәм рус телләрендә бердәй әйтелешле авазлар [б ], [ п ], [д ], [т ], [ ж ], [ з ], [с ], [ и ], [й ], [л ], [м ], [ н ], [р ] , [у ], [ф ] , [ц ] , [щ ] белән танышу, алар кергән сүзләрне дөрес уку.<br>[а ] [о ] [w ] [гъ ] [къ ] [х ] [ч ] [ы ] авазларының әйтелеш үзенчәлекләре һәм бу авазларны язуда дөрес күрсәтү.<br>Татар телендәге [ә ], [ө ], [ү ], [җ ], [ң ], [һ ] авазлары кергән сүзләрне, сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне дөрес уку. |
| **3. Грамматика**<br>Дөрес язу һәм сөйләм күнекмәләре булдыру.<br>Иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес итеп әйтү һәм язу. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, аларны юлдан-юлга күчерү.<br>Калын һәм нечкә сузыкларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы.<br>Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы.<br>Сүз басымын дөрес кую.<br>Татар телендәге исем, фигыль, сыйфат сүз төркемнәре белән таныштыру. Аларның мәгънәләрен аңлату, сорауларын әйтү, уртаклык һәм ялгызлык исемнәрнең |

| |
|---|
| язылышындагы үзенчәлекне күрсәтү. Фигыльләрнең барлык-юклык формалары турында төшенчә бирү.<br>Җөмлә турында гомуми мәгълүмат бирү. Сөйләмне барлыкка китерүдә җөмләнең әһәмиятен аңлату. Анда сүзнең кем яки нәрсә турында баруын һәм алар турында нинди яңалык хәбәр ителүен белдерә торган кисәкләрне күрсәтү. Аерым сүзләрдән җөмләләр төзү, сүзләр арасындагы бәйләнешне аңлату.<br>Төрле интонация белән әйтелгән җөмләләрдән соң куелган тыныш билгеләре белән таныштыру.<br>Бирелгән тексттан сүз,сүзтезмә һәм җөмләләрне дөрес итеп күчереп язу. Аннан соң аларны укытучы әйтүе буенча язу, ул тәкъдим иткән сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзеп язу.<br>Аерым темалар буенча өйрәнгән сүзләрне, сүзтезмә һәм җөмләләрне диктант итеп язу. Матур язу күнегүләрен үтәү. Сөйләм күнекмәләре булдыру өстендә даими эшләү. |

**III. Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру**

| **№** | **Дәрес темасы** | Уку эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Танышу дәресе | Диалог, укытучы белән әңгәмә | 4.09 | |
| 2 | Сөйләмдә зат алмашлык ларын куллану | Диалог төзү,төркемдә эш | 7.09 | |
| 3 | Мәктәп, сыйныф укучылары һәм укытучылар | Диалог, парлап эш | 11.09 | |
| 4 | Бу кем? Бу нәрсә? сораулары | Рәсемнәр белән эш. Сөйләм телен үстерү. Сүзлек. | 14.09 | |
| 5 | Нинди? Ничә? Кая? Кайда? сораулары | Диалог, парлап эшләү уеннар | 18.09 | |
| 6 | Нишли? Нәрсә укый? Нәрсә белән? сораулары | Рәсем белән эш | 21.09 | |
| 7 | Ничек? соравы | Диалог, парлап эшләү Рәсем белән эш | 25.09 | |
| 8 | Гаилә кешеләре | Диалог, укытучы белән әңгәмә | 28.09 | |
| 9 | Ашамлык лар кибетендә | Рәсем белән эш, видео карау әңгәмә | 2.10 | |
| 10 | Тән төзелеше | Рәсем белән эш,уен | 5.10 | |
| 11 | Шәхси гигиена | Диалог, укытучы белән әңгәмә,уен | 9.10 | |
| 12 | Көндәлек режим | Анализлау, нәтиҗә чыгару,рәсем ясау | 12.10 | |
| 13 | Өс-баш киемнәре | Уеннар уйнау | 16.10 | |
| 14 | Аяк киемнәре | Рәсемнәр белән эшли белү. Сөйләм телен үстерү. Сүзлек хәзинәсен арттыру. | 19.10 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 15 | Киемнәр кибетендә | Диалог, парлап эшләү | 23.10 | |
| 16 | Уеннар, уенчыклар | Рәсем белән эш | 26.10 | |
| 17 | Яраткан уенчыгым | Уенчыкны тасвирлау | 30.10 | |
| 18 | Авылда. Яшелчәләр,җиләк-җимешләр. | Диалог, парлап эшләү, төркемнәрдә уеннар | 9.11 | |
| 19 | Йорт кошлары, хайваннары | Презентация, интерактив уеннар | 13.11 | |
| 20 | Кыргый хайваннар | Театр уены | 16.11 | |
| 21 | Кошлар | Парлап эшләү, төркемдә эш | 20.11 | |
| 22 | Бездә кышлаучы һәм җылы якка очучы кошлар | Табышмак табу, презентация | 23.11 | |
| 23 | Шәһәр тормышы на караган атамалар | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 27.11 | |
| 24 | Шәһәр тормышы | Диалог, парлап эшләү Рәсем белән эш | 30.11 | |
| 25 | Шәһәр транспорты | Диалог, парлап эшләү, төркемнәрдә | 4.12. | |
| 26 | Милли бәйрәмнәр | Презентация, интерактив уеннар | 7.12 | |
| 27 | Сабантуй-татар халкының милли бәйрәме | Театр уены,китап белән эш | 11.12 | |
| 28 | Милли бәйрәмнәр дәге уеннар. | Парлап эшләү, төркемдә эш | 14.12 | |
| 29 | [а] авазы һәм А, а хәрефләре | Табышмак табу, презентация | 18.12 | |
| 30 | [ә] авазы һәм Ә,ә хәрефләре | Рәсемнәр буенча парлап эш, төркемнәрдә эш | 21.12 | |
| 31 | [ы] авазы һәм Ы, ы хәрефләре | Парлап эшләү, төркемдә эш | 25.12 | |
| 32 | [ у] авазы һәм У, у хәрефләре | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 11.01 | |
| 33 | [ ү] авазы һәм Ү, ү хәрефләре | Дәфтәрләрдә эш , өстәмә әдәбият белән эш | 15.01 | |
| 34 | [ н] авазы һәм Н, н хәрефләре . Язу. | Театр уены | 18.01 | |
| 35 | [с] авазы һәм С,с хәрефләре | Парлап эшләү, төркемдә эш | 22.01 | |
| 36 | [к] авазы һәм К, к хәрефләре | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 25.01 | |
| 37 | [йы] авазы һәм Е,е хәрефләре | Диалог, парлап эшләү, төркемнәрдә | 29.01 | |
| 38 | [ г ] авазы һәм Г, г хәрефләре | Театр уены,китап белән эш | 1.02 | |
| 39 | [ч] авазы һәм Ч, ч хәрефләре | Табышмак табу, презентация | 5.02 | |
| 40 | [ о] авазы һәм О, о хәрефләре | Рәсемнәр буенча парлап эш, | 8.02 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төркемнәрдә эш. | | |
| 41 | [ ө] авазы һәм Ө, ө хәрефләре | Парлап эшләү, төркемдә эш | 19.02 | |
| 42 | [ э] авазы һәм Э, э хәрефләре | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 22.02 | |
| 43 | [н] авазы һәм ң хәрефе | Дәфтәрләрдә эш , өстәмә әдәбият белән эш | 26.02 | |
| 44 | [йа] авазы һәм Я я хәрефе | Театр уены | 1.03 | |
| 45 | [йу, йү] авазы һәм Ю ю хәрефе | Табышмак табу, презентация | 5.03 | |
| 46 | [в,w]авазлары һәм В в хәрефе | Диалог, парлап эшләү Рәсем белән эш | 8.03 | |
| 47 | Ъ билгесе | Презентация, интерактив уеннар | 12.03 | |
| 48 | Ь билгесе | Парлап эшләү, төркемдә эш | 15.03 | |
| 49 | [ж ] авазы һәм Җ җ хәрефе | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 19.03 | |
| 50 | [ h] һәм Һ, һ хәрефе | Дәфтәрләрдә эш , өстәмә әдәбият белән эш | 22.03 | |
| 51 | Й хәрефе, [й] авазы, әлеге авазларны язу. | Табышмак табу, презентация | 2.04 | |
| 52. | Хәрефләр патшалы гында | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 5.04 | |
| 53 | Әлифбаны “озату” | Рәсемнәр буенча парлап эш, төркемнәрдә эш | 9.04 | |
| 54 | Сөйләм. Аралашу әдәбе. | Дәфтәрләрдә эш , өстәмә әдәбият белән эш | 12.04. | |
| 55 | Сүз. Сүз һәм иҗек. | Презентация, интерактив уеннар | 16.04 | |
| 56 | Авазлар һәм хәрефләр. | Театр уены | 19.04 | |
| 57 | Алфавит. Алфавитны күчереп язу. | Парлап эшләү, төркемдә эш | 23.04 | |
| 58 | Баш хәрефтән языла торган сүзләр.<br>Күчереп язу “Татарстан” | Табышмак табу, презентация | 26.04 | |
| 59 | Хаталар өстендә эш.Сузык авазлар. | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 30.04 | |
| 60 | Тартык авазлар. | Диалог, парлап эшләү Рәсем белән эш | 3.05 | |
| 61 | Сүзләрне юлдан-юлга күчерү. | Диалог, парлап | 7.05 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | эшләү, төркемнәрдә | | |
| 62 | Сузык аваз хәрефләрен дөрес уку һәм язу. | Презентация, интерактив уеннар | 10.05 | |
| 63 | Я,ю,е хәрефләре | Театр уены,китап белән эш | 14.05 | |
| 64 | . Диктант “Май ае” | Парлап эшләү, төркемдә эш | 17.05 | |
| 65 | Хаталар өстендә эш. Й, в,к,г хәрефләренең дөрес язылышы. | Табышмак табу, презентация | 21.05 | |
| 66 | Йомгаклау дәресе | Картина буенча сөйләшү,әңгәмә | 24.05 | |